КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 август г.Казань № 614

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2021 ел, 5 июль, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2021 ел, 05 июль, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 август, 783 нче, 2023 ел, 30 март, 380 нче, 2023 ел, 1 ноябрь, 1387 нче, 2025 ел, 19 июль, 530 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс

ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибендә:

1 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә башка мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның тормышын турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне) яисә башка мәсьәләләрне» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның икенче абзацында «санында төркем» сүзләрен «санында булган затлар төркеме» сүзләренә, «16 яшь» сүзләрен «18 яшь» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «(алга таба - башкарма комитет)» сүзләрен «(алга таба - Башкарма комитет)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составында:

комиссия составыннан Р.Р.Хәбиповны чыгарырга;

комиссия составына Гайнуллов Рөстәм Рафаил улын – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасарын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 16 август, 614 нче карары редакциясендә)

Форма

Гариза

________________________________________________ территориясендә гамәлгә ашыру күздә тотыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар хисабына финанс ярдәм алу өчен тәкъдим ителә торган инициатив проектны (алга таба - инициатив проект) ______________________________, _________ (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме)

| Т/с | Күрсәткечләр | Инициатив проект буенча мәгълүмат |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме | |
| 2. | Инициатив проектны гамәлгә ашыру урыны | |
| 3. | Инициатив проект исеме | |
| 4. | Инициатив проект инициаторы | |
| 5. | Инициатив проектны тасвирлау (проблеманы тасвирлау һәм аның актуальлеген (кискенлеген) нигезләү) | |
| 6. | Күрсәтелгән проблеманы хәл итү буенча тәкъдимнәрне нигезләү | |
| 7. | Инициатив проектның бәясе, шул исәптән җирле һәм төбәк бюджетлары акчалары исәбеннән | |
| 8. | Инициатив проектның максаты һәм бурычы | |
| 9. | Инициатив проектны гамәлгә ашыру чаралары тасвирламасы | |
| 10. | Көтелә торган нәтиҗәләрне тасвирлау | |
| 11. | Инициатив проект нәтиҗәләреннән файдаланачак халык төркемнәре (мөмкин булганда кеше санын - иминлекләрдән турыдан-туры файдаланучыларны билгеләргә) | |
| 12. | Инициатив проектны гамәлгә ашыру срогы | |

______________________ ______________________________

(имза) (инициаллары, фамилиясе)

______________________________